Управление образования исполнительного комитета НМР РТ
Муниципальное бюджетное учреждение дополнительного образования
«Центр внешкольной работы» для одарённых детей НМР РТ

ПРИНЯТО
на заседании методического совета
протокол №__1__ от __01.09.__2023г.

УТВЕРЖДЕНО
Директор МБУ ДО «ЦВР»
для одарённых детей НМР РТ
_____________ /З.А. Санникова
Введено в действие приказом
№__50__ от __01.09.__2023г.

**Дополнительная**
**общеобразовательная общеразвивающая программа**
**социально-гуманитарной направленности**

# ДЕТСКОЕ ОБЪЕДИНЕНИЕ
# «Туган тел»

**Год обучения:** второй
**Возраст воспитанников:** 12-16 лет, 6-11 класс
**Срок реализации:** 1 год

Составила
педагог дополнительного образования
высшей квалификационной категории
Хайруллина Гульназ Рашитовна

г. Нижнекамск, 2023г.

**Дополнительная общеобразовательная общеразвивающая программа социально-гуманитарной направленности**
**“Кызыклы грамматика”**

**Аңлатма язуы**

Өстәмә белем бирү программасы түбәндәге дәүләт документларына нигезләнеп язылды:

- Федеральный Закон от 29.12.2012 г. № 273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации» (с изм. от 17 февраля 2023 года № 26-ФЗ);
- Закон Республики Татарстан «Об образовании» от 22.07.2013 г. № 68-ЗРТ (с изм. от 06.04.2023 года № 24-ЗРТ);
- Закон Республики Татарстан «О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан» от 08.07.1992 г. № 1560-XII (с изм. от 06.04.2023 года № 24-ЗРТ);
- Закон Республики Татарстан «Об отдельных мерах по защите прав и законных интересов ребенка в Республике Татарстан» от 29.04.2022 г. № 26-ЗРТ (с изм. от 06.04.2023 N 32-ЗРТ);
- Приказ Министерства просвещения РФ от 27 июля 2022 года № 629 «Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по дополнительным общеобразовательным программам»;
- Концепция общенациональной системы выявления и развития молодых талантов на 2015-2020 годы (утверждена Президентом Российской Федерации 3 апреля 2012 г. № Пр-827) и комплекс мер по ее реализации (утвержден Правительством Российской Федерации 27 мая 2015 г. № 3274п-П8);
- «Методические рекомендации по проектированию дополнительных общеразвивающих программ (включая разноуровневые программы)» (Письмо Департамента государственной политики в сфере воспитания детей и молодёжи МОиН РФ от 18.11.2015 г. № 09-3242);
- «Методические рекомендации по проектированию и реализации дополнительных общеобразовательных программ» Письмо МОиН РТ от 07.03.2023 г. № 2749/23;
- «Требования к содержанию и оформлению образовательных программ дополнительного образования детей» Письмо от 18.06.2003 г. № 28-02-484/16;
- Стратегия развития воспитания в Российской Федерации на период до 2025 года, утвержденная Распоряжением Правительства Российской Федерации от 29 мая 2015 г. № 996-р.;
- Стратегическая инициатива «Новая модель системы дополнительного образования», одобренная Президентом Российской Федерации 27 мая 2015 г.;
- Государственная программа Российской Федерации «Развитие образования», утвержденная Постановлением Правительства Российской Федерации от 26 декабря 2017 года № 1642 (изм. Постановлением Правительства Российской Федерации от 27 февраля 2023 года № 312) ;
- Федеральный Закон Российской Федерации «Об основных гарантиях прав ребёнка в Российской Федерации» от 24.07.1998 г. № 124-ФЗ (с изм., от 3 апреля 2023 года

№ 96-ФЗ);

- Приказ МОиН РТ от 20 марта 2014 г. № 1465/14 «Об утверждении Модельного стандарта качества муниципальной услуги по организации предоставления дополнительного образования детей в многопрофильных организациях дополнительного образования в новой редакции»;
- Приказ Министерства просвещения РФ от 3 сентября 2019 г. N 467 «Об утверждении Целевой модели развития региональных систем дополнительного образования детей» (с изм., приказ Минпросвещения России от 2 февраля 2021 года № 38);
- Приказ Министерства труда и социальной защиты Российской Федерации от 22 сентября 2021 года № 652н «Об утверждении профессионального стандарта «Педагог дополнительного образования детей и взрослых»;
- Приказа МОиН РТ от 19.05.2021 г. № под-732/21 «О внедрении Навигатора дополнительного образования Республики Татарстан»;
- Национальный проект «Образование», утвержденный на заседании президиума Совета при Президенте Российской Федерации по стратегическому развитию и национальным проектам (протокол от 24 декабря 2018 г. № 16);
- Федеральный проект «Успех каждого ребенка», утвержденный президиумом Совета при Президенте Российской Федерации по стратегическому развитию и национальным проектам (протокол от 24 декабря 2018 года № 16);
- Постановление Главного государственного санитарного врача РФ от 28.09.2020 г. №28 «Санитарно-эпидемиологические требования к организациям воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодежи» (Санитарные правила 2.4.3648-20);
- «Концепция развития дополнительного образования детей» Распоряжение Правительства Российской Федерации от 31.03.2022 г. № 678-р;
- Программа развития МБУ ДО «Центр внешкольной работы» для одаренных детей НМР РТ на 2022-2030 уч.гг.;
- Устав МБУ ДО «Центр внешкольной работы» для одарённых детей НМР РТ;
- Локальные нормативные акты Центра, утвержденные в 2021 году, с дополнениями и изменениями в 2023 году.

Социаль-гуманитар булган өстәмә белем бирү программасында укытуның традицион булмаган яңа формаларына һәм алымнарына зур игътибар бирелә. Бу юнәлештә балаларның белем һәм күнекмәләрен тикшерүдә объектив һәм уңайлы ысулларның берсе булган тестлар аеруча киң файдаланыла. Тестлар ике бүлектән тора: теориягә караган тест сораулары һәм гамәли тест сораулары. Тестлар “җиңелдән-авырга” принцибы буенча биреләчәк. Тестлар белән беррәттән, грамматик биремнәр, проект эшләре башкару да каралган.

Балаларның аралашу сәләтен, иҗадилыгын үстерү өстендә эшләүгә өстенлек бирү әлеге программаны гадәтидән аерып тора. Бу юнәлештә эшләү балага үзен шәхес буларак югары бәяләргә мөмкинлек бирәчәк, чөнки программаны уңышлы үзләштергән очракта бала конкурентлыкка сәләтле, грамоталы, заман таләпләренә җавап бирерлек шәхес буларак формалаша. Бу программаның **актуальлеген** күрсәтә.

Теория белән беррәттән гамәли биремнәр башкару да күздә тотыла. Мисалларның татар әдәбияты әсәрләреннән, вакытлы матбугаттан, фольклор әсәрләреннән, мәкальләрдән, халык җырларыннан һәм шулай ук сөйләм теленнән алынуы, балаларны проект эшенә, өстәмә эзләнүгә этәрү, рус әдәбияты белән бәйләнештә карау программаның **яңалыгы** булып тора.

Программаның **педагогик максатчанлыгы**: теоретик материал иҗади практика белән бәйләнеп бара; бала үз эшенә бурыч куя һәм аны чишү юлын үзе сайлый; бала практик эшне башкарганда теоретик материалны һәрдаим яңартып-искә төшереп тора - бу үз чиратында иҗади тонусны арттыра. Баланың иҗади фикерләү сәләте үсә, төрле яшь үзенчәлеге булган балаларда лидерлык күнекмәләре, толерантлылык арта. Эзләнү-тикшеренү эшләре балаларда төркем эшчәнлегенең катлаулы бурычларын хәл итүдә тәҗрибә өсти, шәхсән һәм төркемдә эшләү күнекмәләре арта.

Өстәмә белем бирү программасы түбәндәге **максатны** куя:
- туган тел өлкәсендә белем һәм тәрбия бирүдә теоретик биремнәрне үзләштерүне гамәли яктан җиңеләйтү;

Өстәмә белем бирү программасы түбәндәге **бурычларны** куя:

**белем бирү бурычы:**
- туган тел фәне өлкәсенә кызыксыну уятуны дәвам итү;
- татар әдәби теленнән белемнәрне тирәнәйтү, сүзлек запасын арттыру;
- олимпиада, фәнни конференция, бәйгеләрдә үз көчеңне сынап карауга кызыксыну аша мотивлаштыруны дәвам итү; туган тел серләренә төшенү өстендә эшләүгә этәргеч бирү.

**тәрбияви бурычлар:**
- тәрбияләнүчедә киңкырлы мәдәни фикер йөртү сәләте формалаштыру;
- ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү;
- китап, фәнни чыганаклар белән эшләү культурасы булдыру.

**үстерелешле бурычлар:**
- зирәклек һәм тапкырлык сыйфатын үстерү;
- мөстәкыйль рәвештә тикшеренү эшенә тарту;
- китап һәм фәнни чыганаклар белән шәхсән һәм төркемдә эшли белү күнемәләре булдыру.

**Программаның үзенчәлеге.** Өстәмә белем бирү программасы баланың югары мотивациясен саклап калуга нигезләнә, туган тел белеме өлкәләренә тирән күзәтү ясый һәм теория белән практиканы үзара бәйләп бирә. Туган тел һәм туган тел әдәбиятының бәйләнешле алып барылуы грамоталы, тирән белемле шәхес тәрбияләүгә йогынты ясый, ике өлкәдә дә тиешле белем туплауга ярдәм итә. Программа шәһәркүләм һәм республикакүләм чараларны исәпкә алып төзелде. Шул сәбәпле, бала бәйге һәм конференцияләрдә алдагы әзерлек белән катнаша ала. Бала программа үтәлешендә психологик уңай шарт тоя.

**Балаларның яшь аралыгы** 12-16 яшь. Программа балаларның яшь үзенчәлеген исәпкә алып төзелде. Балалар иҗади сәләтләренә карап оештырылды, конкурска нигезләнү булмады. Состав һәр ел үзгәрергә мөмкин. Төркемдә 12 бала.

**Программа сроклары**: 36 атнага 6 сәгать исәбеннән 216 сәгатькә төзелде. 15 нче сентябрьдән 31нче майга кадәр вакыт аралыгында үткәрү күздә тотыла. Материаллар шул вакыт аралыгында үзләштереп бетерерлек итеп алынды.

Өстәмә белем бирү буенча занятиеләр 1нче  гимназиянең 305нче кабинетында үткәрелә.

Балалар оешмасы бюджетлы муниципаль өстәмә белем бирү оешмасы “Сәләтле балалар белән эшләүче мәктәптән тыш үзәге”  нигезендә эшли.

Программаны тормышка ашыруның планлаштырылган вакыты нәтиҗәләргә ирешү өчен тормышка ашырыла.

**Занятиеләрнең режимы һәм формасы.** Елга 216 сәгать исәбеннән төзелде. Атнага 6 сәгать итеп 3 көн үткәрелә. Эшчәнлек формасына килгәндә, темага карап төркемдә һәм шәхси итеп үткәрелә.

Занятиеләр атнага 3 тапкыр (көненә 2 сәгатьтән артык түгел) үткәрелә. Занятие дәвамлыгы – 40 минут, занятиеләр арасында 10 минутлык тәнәфес каралган.
Эшне оештыру формалары: төркемдә, индивидуаль, парларда алып барылачак.

***Электрон укыту һәм дистанцион белем бирү технологияләрен куллану (ЭО и һәм ДОТ)***

Үзәктә өстәмә гомуми белем бирү һәм гомуми үстерү программаларын гамәлгә ашыруда электрон укыту һәм дистанцион белем бирү технологияләрен куллануның максаты: Үзәктә тәрбияләнүчеләргә, кайда яшәвенә-вакытлыча тукталуына, сәламәтлегенә, иҗтимагый катламына, шулай ук гадәттән тыш шартларга (ЧС, карантин һ.б.ш.) карамастан, чикләүсез, сыйфатлы белем алуга бердәм мәгълүмати-белем бирү мохите тудыру.

Өстәмә гомуми белем бирү һәм гомуми үстерү программаларында электрон укыту һәм дистанцион белем бирү технологияләрен куллану чагылыш таба һәм түбәндәге формалар кулланылырга мөмкин:
- консультация;
- лекция;
- семинар;
- практик занятие;
- лаборатор эш;
- контроль эш;
- аудиториядән тыш мөстәкыйль эш;
- фәнни-тикшеренү эшләре.

**Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр**

- бала татар теле һәм әдәбияты аша телнең милли үзаңны белдерүгә нигез булуын күзаллый;
- укучыларда телдән һәм язма сөйләмне дөрес итеп төзүгә уңай караш тәрбияләнә, алар аны шәхеснең тәрбияле булу билгесе итеп кабул итә;
- туган телдә (татар телендә) орфоэпик, лексик һәм грамматик төшенчәләрне, сөйләм әдәбе кагыйдәләрен үзләштерә, аралашуның максат һәм бурычларыннан чыгып, тиешле тел берәмлекләреннән урынлы итеп файдалана белә;
- аралашу вакытында өйрәнелгән тел берәмлекләрен танып-белү һәм гамәли максатлардан чыгып файдалана;
- төрле чыганаклар белән иректе эш алып бара.

**Мониторинг. Контроль төре.**
**Әлеге программаны тулысынча гамәлгә кую өчен төрле контроль төрләре кулланыла:**

- башлангыч (яки кереш) контроль баланың үсеш дәрәҗәсен билгеләү өчен үткәрелә;
- агымдагы – баланың занятиеләр үткәрү барышындагы эшчәнлеген тикшерү өчен гамәлгә ашырыла;
- арадаш – занятие-зачет, тест, проект яклау;
- гомуми – комплекслы тикшерү эше.

Баланың программа үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү максатыннан, **инша, рәсем** (билгеле темаларга багышлап), **проект эше** (табышмаклар, синтаксик берәмлекләр, курс тәмамлангач гомуми эш проекты көтелә), **шигырь язу, тәрҗемәләр белән эшләү** кебек эш төрләре кулланыла. Балаларның белемнәрен мониторинглау максатыннан, кереш контроль эш, арадаш һәм йомгаклау биремнәре башкару күздә тотыла. Олимпиада, конкурс, конференцияләрдә актив катнашу, проект эшләре яклау көтелә.

**Йомгаклау ясау формалары.** Программаны үзләштергәннән соң баланың катнашкан бәйге, олимпиада һәм конференцияләреннән чыгып, йомгак ясала. Нинди нәтиҗәләргә ирешкән, диплом, грамоталары исәпләнә. Диагностик карта ярдәмендә шәхси үсеше бәяләнә. Бу программа үзләштерү алдыннан һәм аннан соң булган үзгәрешләрен мониторинглау өчен уңайлы.

***<u>216 сәгать исәбеннән Туган тел фәненнән укыту планы</u>***

| № | **Бүлек исеме, тема** | **Сәгать саны** | **Теория** | **Практика** | **Контроль формасы** |
|---|---|---|---|---|---|
| **1.** | **Кереш занятие** | **1** | **1** | | |
| 1.1. | Куркынычсызлык техникасы белән танышу. 3нче сентябрь - Террорчылык белән көрәштә теләктәшлек көне | 1 | 1 | | |
| **2.** | **Орфографик принципларның әдәби әсәрдә чагылышы** | **11** | **4** | **7** | **Контроль биремнәр** |
| 2.1 | Әдәби әсәрләрдән әйтелеше һәм язылышы туры килмәгән очраклар табу | 2 | 1 | 1 | |
| 2.2 | Орфографиянең кыен очракларына мисаллар туплау | 1 | 1 | | |
| 2.3. | Татар халык авыз иҗатыннан орфографик принципларга мисаллар табу | 4 | 1 | 3 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2.4. | Татар һәм рус телләренең орфографиясен чагыштыру | 2 | 1 | 1 | |
| 2.5. | Орфографик сүзлекләр куллану үзенчәлеге | 2 | | 2 | |
| **3.** | **Төрле жанрдагы әсәрләргә лингвистик анализ** | **8** | **2** | **6** | **Текст анализы** |
| 3.1. | Лингвистик анализ үрнәкләре белән таныштыру | 2 | 2 | | |
| 3.2. | Төбәк әдипләренең әсәрләренә лингвистик анализ ясау | 3 | | 3 | |
| 3.3 | Балалар иҗаты конкурсы «Мы будем вечно прославлять ту женщину, чьё имя Мать!» - «Ана-бөек исем!», посвящённый Дню матери» | 3 | | 3 | **Инша, рәсем** |
| **4.** | **Иҗади үстерүдә табышмакларның роле** | **10** | **2** | **8** | **Проект эше** |
| 4.1. | Шигъри формада табышмаклар уйлап чыгару | 4 | 2 | 2 | |
| 4.2. | Табышмак әйтәм-тап бәйге-уены | 2 | | 2 | |
| 4.3 | Табышмаклар буенча төрле форматта проект эше башкару | 4 | | 4 | |
| **5.** | **Лексикология** | **18** | **6** | **12** | **Шигъри юллар** |
| 5.1. | Сүз уйнату | 4 | 2 | 2 | |
| 5.2. | Омонимнарның төрләрен кулланып, шигъри юллар иҗат итү | 6 | 2 | 4 | |
| 5.3. | Күпмәгънәле  сүзләр һәм туры мәгънә белән күчерелмә мәгънә: аерма һәм охшашлыклары | 4 | 2 | 2 | |
| 5.4. | Шәүкәт Галиев иҗатында сүз уйнату алымнары. ТР Конституциясе көне . “Балаларның Интернет челтәрендә куркынычсызлыгы” Бөтенрәсәй дәресе | 4 | | 4 | |
| **6.** | **Морфология** | **14** | **2** | **12** | **Тест** |
| 6.1. | Г.Тукайның “Ана догасы” шигырендә исем сүз төркеменең кулланылышын билгеләү. | 2 | | 2 | |
| 6.2. | Ә.Еникинең “Әйтелмәгән васыять” әсәрендә сыйфат сүз төркеменең функциясен ачыклау. | 2 | | 2 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 6.3. | Г.Сабитов әсәрләрендә алмашлыкларның кулланылышын билгеләү. | 2 | | 2 | |
| 6.4. | Әкиятләрдә фигыль формаларының бирелешен ачыклау. | 4 | | 4 | |
| 6.5. | Аваз ияртемнәреннән яңа сүзләр ясау. | 2 | 1 | 1 | |
| 6.6 | Халык авыз иҗаты буенча тестлар һәм биремнәр төзү. | 2 | 1 | 1 | |
| **7.** | **Синтаксик берәмлекләр** | **42** | **10** | **32** | **Проект эше** |
| 7.1. | Ш.Камалның “Буранда” әсәре аша әйтелү максаты ягыннан җөмлә төрләрен билгеләү. | 4 | 2 | 2 | |
| 7.2. | Ш.Камалның “Буранда” әсәре аша раслау һәм инкяр җөмләләрне табу, үзгәртү. | 4 | 2 | 2 | |
| 7.3. | Ә.Еники әсәрләре аша җыйнак һәм җәенке җөмләләрне билгеләү. | 2 | 1 | 1 | |
| 7.4. | Ике һәм бер составлы җөмләләрнең мәкаль-әйтемнәрдә кулланылышын билгеләү. | 4 | 2 | 2 | |
| 7.5. | Гади һәм кушма җөмләләрнең татар әдәбиятында кулланылышын билгеләү. 12нче декабрь - РФ Конституциясе көне | 2 | 1 | 1 | |
| 7.6. | Татар һәм рус әдәбияты әсәрләрендә синтаксик күренешләрне тикшерү, чагыштыру | 4 | 2 | 2 | |
| 7.7. | Г.Тукай һәм А.Пушкин әсәрләрен чагыштыру. | 4 | | 4 | |
| 7.8. | Г.Ибраһимов һәм Л.Толстой әсәрләрен чагыштыру. | 4 | | 4 | |
| 7.9. | Җөмләнең төрләре буенча төрле форматта проект башкару. | 4 | | 4 | |
| 7.10 | Составында аерымланган кисәк булган җөмләләрдә тыныш билгеләрен билгеләү, әдәби әсәрләрдән табу. | 2 | | 2 | |
| 7.11 | Г.Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр” әсәрендә тиңдәш кисәкләр булган җөмләләр; | 2 | | 2 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | аларда тыныш билгеләре. | | | | |
| 7.12 | Әдәби әсәрдә аныклагыч булган җөмләләр; аларда тыныш билгеләре. | 2 | | 2 | |
| 7.13 | Драма әсәрләрендә кереш яки эндәш сүзе булган җөмләләр; аларда тыныш билгеләре. | 2 | | 2 | |
| 7.14 | Халык авыз иҗаты, халык йолалары буенча «Аулак өй кичләре» | 2 | | 2 | |
| **8.** | **Сөйләм культурасы һәм сөйләм стильләре** | **74** | **31** | **43** | **Тәрҗемә текстлары** |
| 8.1. | Функциональ сөйләм стильләре. | 2 | 2 | | |
| 8.2. | Сөйләшү һәм язма стиль. | 2 | 1 | 1 | |
| 8.3. | Хат язу. | 4 | 2 | 2 | |
| 8.4. | Экспрессив сөйләм стильләре. | 2 | 2 | | |
| 8.5. | Күтәренке стиль. Түбәнәйтелгән стиль. Төрле жанрдагы әсәрләрне төрлечә уку. | 4 | | 4 | |
| 8.6. | Нәзәкатьле сөйләм стиле. Дусларча ягымлы сөйләм стиле. | 4 | 2 | 2 | |
| 8.7. | Рәсми- салкын стиль. Юмор һәм сатира стиле. | 4 | 2 | 2 | |
| 8.8. | Сөйләшү стиленең фонетик үзенчәлекләре. Дикция өстендә эшләүнең әһәмияте. | 2 | 1 | 1 | |
| 8.9. | Басым. Артикуляция гимнастикасы. Сузык авазлар. | 2 | 1 | 1 | |
| 8.10. | Артикуляция гимнастикасы. Тартык авазлар. | 2 | 1 | 1 | |
| 8.11. | Тизәйткечләр аша сөйләмне камилләштерү | 4 | 1 | 3 | |
| 8.12. | Сәхнә теле логикасы. Интонация. Сулышта булган кимчелекләр. | 2 | 1 | 1 | |
| 8.13 | Сәнгатьле уку. Күңел, пейзаж, гражданлык лирикасында интонация. | 4 | 2 | 2 | |
| 8.14 | Алынма сүзләр. Алынма сүзләрнең әйтелеше һәм язылышы. | 4 | 2 | 2 | |
| 8.15 | Урынсыз кулланган рус сүзләре. Гади сөйләм сүзләре һәм диалектизмнар. | 4 | 1 | 3 | |
| 8.16 | Кайбер сүзләрнең һәм | 4 | 2 | 2 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | терминнарның татарчага тәрҗемәләре. | | | | |
| 8.17. | Морфология күренешләре. Дөрес сөйләм. | 2 | 1 | 1 | |
| 8.18. | Сөйләм культурасы, интонация һәм синтаксис. | 2 | 2 | | |
| 8.19. | Рус һәм татар теле җөмләләренең кайбер үзенчәлекләре.Тәрҗемә үзенчәлекләре. | 2 | | 2 | |
| 8.20. | Сөйләм интонациясе һәм стиль мәсьәләләре. Интонация төзүдә кушымчаларның роле. | 2 | 1 | 1 | |
| 8.21. | Ярдәмлек сүзләр һәм интонация. Сөйләмнең табигый агышында “артык” сүзләр. | 2 | 1 | 1 | |
| 8.22. | Телефоннан сөйләшү этикеты | 4 | | 4 | |
| 8.23 | Стиль чарасы буларак кабатлаулар, әдәби әсәрдән мисаллар белән ныгыту. | 2 | 1 | 1 | |
| 8.24 | Сөйләм интонациясе һәм инверсиянең бер-берсенә бәйләнеше. | 2 | 1 | 1 | |
| 8.25 | Төрле жанрларга аннотация язу: музыка, рәсем, әдәби әсәр, спекакль, балет һ.б.ш. | 6 | 1 | 5 | |
| **9.** | **Китап белән эшләү** | **24** | 8 | 16 | |
| 9.1. | Китапның төзелеше. Төп терминнар | 6 | 2 | 4 | |
| 9.2. | Китап уку кагыйдәләре | 4 | 2 | 2 | |
| 9.3 | Язучының тормыш юлын өйрәнү планы | 2 | 1 | 1 | |
| 9.4 | Яраткан әсәрең турында сөйләү планы | 2 | 1 | 1 | |
| 9.5 | Аннотация, отзыв, конспект, доклад, рецензия, реферат язу | 10 | 2 | 8 | |
| **10** | **Олимпиада, бәйге, конференцияләрдә катнашу, төрле чаралар** | **12** | **6** | **6** | |
| 10.1 | “Юл һәлакәте корбаннары” истәлегенә көзге, кышкы, язгы, җәйге каникуллар алдыннан чара. “Гражданнар оборонасы көне” | 4 | 4 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 10.2 | Югары сыйныф укучылары өчен республикакүләм фән олимпиадаларында катнашу | 2 | | 2 | |
| 10.3 | Урта сыйныф укучылары өчен республикакүләм фән олимпиадаларда катнашу | 2 | | 2 | |
| 10.4 | Башлангыч һәм урта звено укучылары өчен “Фәнгә беренче адым” XI Республикакүләм тикшеренү һәм проект эшләре конференциясе | 2 | 1 | 1 | |
| 10.5 | “Мин-эзләнүче” X Иделбуе яшүсмерләр фәнни-тикшеренү конференциясендә катнашу | 2 | 1 | 1 | |
| **11** | **Йомгаклау. Курс буенча проект эше** | **2** | **1** | **1** | **Проект эше** |
| | **Барлыгы:** | **216** | **73** | **143** | |

***Вакыт бүленеше схемасы:***

| № | Продолжительность занятия | Периодичность в неделю | Кол-во час./занятий в неделю | Кол-во часов/занятий в год |
|---|---|---|---|---|
| 1. | 2сәгать/2часа | 3 тапкыр/3раза | 6 сәг/6 занятий | 216 сәг/216 занятий |

**Эчтәлек.**

**Тема 1.1.** Куркынычсызлык техникасы белән танышу. 3нче сентябрь - Террорчылык белән көрәштә теләктәшлек көне

**Тема 2.1** Әдәби әсәрләрдән әйтелеше һәм язылышы туры килмәгән очраклар табу.

**Теория.** Әйтелеше һәм язылышы туры килмәгән очракларны аңлату.

**Тема 2.2.** Орфографиянең кыен очракларына мисаллар туплау.

**Теория.** Орфографиянең кыен очракларын билгеләү.

**Тема 2.3.** Татар халык авыз иҗатыннан орфографик принципларга мисаллар табу

**Теория.** Орфографиянең кыен очракларын билгеләү.

**Практика.** Әкият, табышмак, әйтемнәрдән орфографик принципларга мисаллар табу.

**Тема 2.4.** Татар һәм рус телләренең орфографиясен чагыштыру.

**Теория.** Ике телнең орфографиясен чагыштыру.

**Практика.** Татар һәм рус теле арасындагы орфографик аермаларны билгеләү.

**Тема 2.5.** Орфографик сүзлекләр куллану үзенчәлеге.
**Практика.** Татар теленең орфографик сүзлекләрен куллану үзенчәлеген билгеләү.
**Тема 3.1.** Лингвистик анализ үрнәкләре белән таныштыру**.**
**Теория.** Лингвистик анализ тәртибе белән таныштыру, алгоритмын үзләштерү.
**Тема 3.2.** Төбәк әдипләренең әсәрләренә лингвистик анализ ясау
**Практика.** Түбән Кама җирлегендә яшәп иҗат итүче әдипләр иҗатын барлау, аларның әсәрләреннән алынган текстлар белән эш. Текст анализы башкару.
**Тема.** Балалар иҗаты конкурсы «Мы будем вечно прославлять ту женщину, чьё имя Мать!» - «Ана- бөек исем!»
**Практика.** «Мы будем вечно прославлять ту женщину, чьё имя Мать!» - «Ана- бөек исем!» балалар иҗаты конкурсы оештыру, төрле материаллардан башкарылган эшләрне тәкъдир итү.
**Тема 4.1.** Шигъри формада табышмаклар уйлап чыгару
**Теория.** Табышмакка билгеләмә бelү, үзенчәлеген аңлату.
**Практика.** Үзлектән табышмак уйлап чыгару.
**Тема 4.2.** Табышмак әйтәм-тап бәйге-уены.
**Практика.** Балалар төркемнәрдә табышмак әйтешәләр, җинүче билгелиләр.
**Тема 4.3.** Табышмаклар буенча төрле форматта проект эше башкару.
Практика. Балаларның үзләре уйлап чыгарган табышмаклары бенча проект эше яклау, кечкенә китаплар чыгару.
**Тема 5.1.** Сүз уйнату.
**Теория.** Шарада, сүз уйнату турында мәгълүмат бирү.
**Практика.** Сүз уйнату аша төрле грамматик конструкцияләр төзү. Татар әдипләренең шарадалары белән танышу.
**Тема 5.2.** Омонимнарның төрләрен кулланып, шигъри юллар иҗат итү.
**Теория.** Омонимнар, омоформалар, омографлар, саф омонимнар турында теоретик белемнәр бирү.
**Практика.** Омонимнар, омоформалар, омографлар, саф омонимнар белән җөмләләр төзү, әдәби әсәрләрдән табу, шигъри юллар иҗат итү.
**Тема 5.3.** Күпмәгънәле сүзләр һәм туры мәгънә белән күчерелмә мәгънә: аерма һәм охшашлыклары.
**Теория.** Күпмәгънәле сүзләр һәм туры мәгънә белән күчерелмә мәгънәне аера белү.
**Практика.** Күпмәгънәле сүзләрне күчерелмә мәгънәдән аеру өчен мисаллар башкару.
**Тема 5.4.** Шәүкәт Галиев иҗатында сүз уйнату алымнары. ТР Конституциясе көне . “Балаларның Интернет челтәрендә куркынычсызлыгы” Бөтенрәсәй дәресе
**Практика.** Шәүкәт Галиев иҗатына күзәтү ясау, сүз уйнату алымнарын билгеләү.
**Тема 6.1.** Г.Тукайның “Ана догасы” шигырендә исем сүз төркеменең кулланылышын билгеләү.
**Практика.** Г.Тукайның “Ана догасы” әсәреннән алынган өзекләр белән эшләү, исем сүз төркеменең кулланылышын билгеләү.
**Тема 6.2.** Ә.Еникинең “Әйтелмәгән васыять” әсәрендә сыйфат сүз төркеме.
**Практика.** Ә.Еникинең “Әйтелмәгән васыять” әсәреннән алынган өзекләр белән эшләү, сыйфат сүз төркеменең кулланылышын билгеләү.
**Тема 6.3.** Г.Сабитов әсәрләрендә алмашлыкларның кулланылышын билгеләү.

**Практика.** Г.Сабитов әсәреннән алынган өзекләр белән эшләү, алмашлык сүз төркемен табу, аның кулланылышын билгеләү.
**Тема 6.4.** Әкиятләрдә фигыль формаларының бирелешен ачыклау.
**Практика.** Әкиятләрдән алынган өзекләр белән эшләү, фигыль сүз төркемен табу, аның кулланылышын билгеләү.
**Тема 6.5.** Аваз ияртемнәреннән яңа сүзләр ясау.
**Теория.** Аваз ияртемнәре, сүз ясагыч кушымчалар турында белемнәрне актуальләштерү.
**Практика.** Сүз ясагыч кушымчалар ярдәмендә аваз ияртемнәреннән яңа сүзләр ясау, алар ярдәмендә җөмләләр төзү.
**Тема 6.6.** Халык авыз иҗаты буенча тестлар һәм биремнәр төзү.
**Теория.** Тест төзү үзенчәлекләрен аңлату, халык авыз иҗаты әсәрләрен барлау.
**Практика.** Халык авыз иҗатыннан алынган өзекләр буенча грамматик биремле тестлар һәм биремнәр төзү.
**Тема 7.1.** Ш.Камалның "Буранда" әсәре аша әйтелү максаты ягыннан җөмлә төрләрен билгеләү.
**Теория.** Әйтелү максаты ягыннан җөмлә төрләрен искә төшерү, белемәрне актуальләштерү.
**Практика.** Ш.Камалның "Буранда" әсәреннән алынган өзекләр өстендә эшләү, әйтелү максаты ягыннан җөмлә төрләрен алмаштырып уку, мәгънә үзгәрүгә игътибар итү.
**Тема 7.2.** Ш.Камалның "Буранда" әсәре аша раслау һәм инкяр җөмләләрне табу, үзгәртү.
**Теория.** Әйтелү максаты ягыннан җөмлә төрләрен искә төшерү, белемәрне актуальләштерү.
**Практика.** Ш.Камалның "Буранда" әсәреннән алынган өзекләр өстендә эшләү, әйтелү максаты ягыннан җөмлә төрләрен алмаштырып уку, мәгънә үзгәрүгә игътибар итү.
**Тема 7.3.** Ә.Еники әсәрләре аша җыйнак һәм җәенке җөмләләрне билгеләү.
**Теория.** Җыйнак һәм җәенке җөмләләр турында белемнәрне искә төшерү, актуальләштерү.
**Практика.** Ә.Еники әсәрләреннән алынган өзекләр аркылы җыйнак һәм җәенке җөмләләрне билгеләү, төрле грамматик конструкцияләр төзеп карау.
**Тема 7.4.** Ике һәм бер составлы җөмләләрнең мәкаль-әйтемнәрдә кулланылышын билгеләү.
**Теория.** Ике һәм бер составлы җөмләләр турында белемнәрне искә төшерү, актуальләштерү.
**Практика.** Мәкаль-әйтемнәр аркылы ике һәм бер составлы җөмләләрне билгеләү, төрле грамматик конструкцияләр төзеп карау.
**Тема 7.5.** Гади һәм кушма җөмләләрнең татар әдәбиятында кулланылышын билгеләү. 12нче декабрь - РФ Конституциясе көне
**Теория.** Гади һәм кушма җөмләләр турында белемнәрне искә төшерү, актуальләштерү.
**Практика.** Татар әдәбияты аркылы гади һәм кушма җөмләләрне билгеләү, төрле грамматик конструкцияләр төзеп карау.

**Тема 7.6.** Татар һәм рус әдәбияты әсәрләрендә синтаксик күренешләрне тикшерү, чагыштыру.
**Теория.** Татар һәм рус телләрендәге төрле грамматик конструкцияләрне чагыштыру, охшаш, аермалы якларын күзәтү.
**Практика.** Ике тел әдәбиятындагы классик әсәрләр үрнәгендә грамматик конструкцияләрне тикшерү.
**Тема 7.7.** Г.Тукай һәм А.Пушкин әсәрләрен чагыштыру.
**Практика.** Рус һәм татар әдәбияты классиклары әсәрләрен чагыштыру. Эшкә төрле юнәлешләр бирү, җөмләнең төрле конструкцияләре буенча тикшерү.
**Тема 7.8.** Г.Ибраһимов һәм Л.Толстой әсәрләрен чагыштыру.
**Практика.** Татар һәм рус әдәбиятындагы классик үрнәкләр ярдәмендә аерымланган кисәкле җөмләләргә мисаллар табу, аларның кулланылыш дәрәҗәсен билгеләү.
**Тема 7.9.** Җөмләнең төрләре буенча төрле форматта проект башкару.
**Практика.** Проект эшенә төрле юнәлешләр бирү, җөмләнең төрле конструкцияләре буенча тикшерү.
**Тема 7.10.** Составында аерымланган кисәк булган җөмләләрдә тыныш билгеләрен билгеләү, әдәби әсәрләрдән табу.
**Практика.** Татар әдәбиятының классик әсәрләре үрнәгендә аерымланган кисәкләрле җөмләләр табып, тыныш билгеләренең куелышын тикшерү.
**Тема 7.11.** Г.Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр” әсәрендә тиңдәш кисәкләр булган җөмләләр; аларда тыныш билгеләре.
**Практика.** Г.Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр” әсәре үрнәгендә тыныш билгеләрен тикшерү, тиңдәш кисәкле җөмләләр табу, әһәмиятен аңлату.
**Тема 7.12.** Әдәби әсәрдә аныклагыч булган җөмләләр; аларда тыныш билгеләре.
**Практика.** Әдәби әсәрләр үрнәгендә тыныш билгеләрен тикшерү, тиңдәш кисәкле җөмләләр табу, әһәмиятен аңлату.
**Тема 7.13.** Драма әсәрләрендә кереш яки эндәш сүзе булган җөмләләр; аларда тыныш билгеләре.
**Практика.** Драма әсәрләр үрнәгендә тыныш билгеләрен тикшерү, эндәш яки кереш кисәкле җөмләләр табу, әһәмиятен аңлату.
**Тема. 7.14.** Халык авыз иҗаты, халык йолалары буенча «Аулак өй кичләре»
**Практика.** Әйтү максаты буенча җөмлә төрләреннән төрле грамматик конструкцияләр кулланып, балалар белән “Аулак өй” кичәләрен кечкенә сәхнәдә уйнап карау.
**Тема 8.1.** Функциональ сөйләм стильләре.
**Теория.** Функциональ сөйләм стильләре турында теоретик белемнәрне актуальләштерү, тирәнәйтү.
**Тема 8.2.** Сөйләшү һәм язма стиль.
**Теория.** Сөйләшү һәм язма стиль турында теоретик белемнәрне актуальләштерү, тирәнәйтү.
**Практика.** Сөйләшү һәм язма стиль арасындагы охшашлык һәм аерманы билгеләү, текстлар өстендә эшләү аша практиканы камилләштерү.
**Тема 8.3.** Хат язу.
**Теория.** Эпистоляр жанр белән таныштыру.
**Практика.** Якын дустыңа, әби-бабайга хат язу.

**Тема 8.4.** Экспрессив сөйләм стильләре.
**Теория.** Экспрессив сөйләм стиле турында теоретик белемнәрне актуальләштерү, тирәнәйтү.
**Тема 8.5.** Күтәренке стиль. Түбәнәйтелгән стиль. Төрле жанрдагы әсәрләрне төрлечә уку.
**Практика.** Сөйләшү стиленең фонетик үзенчәлекләрен исәпкә алып, төрле текстарны уку; дикцияне камилләштерү өчен бер үк текстны төрле стиль белән уку.
**Тема 8.6.** Нәзәкатьле сөйләм стиле. Дусларча ягымлы сөйләм стиле.
**Теория.** Нәзәкатьле сөйләм, дусларча ягымлы сөйләм стильләре турында теоретик белемнәрне актуальләштерү, тирәнәйтү.
**Практика.** Үзара сөйләшү аша практик күнегүләр башкару.
**Тема 8.7.** Рәсми-салкын стиль. Юмор һәм сатира стиле.
**Теория.** Рәсми-салкын стиль, юмор һәм сатира стиле турында теоретик белемнәрне актуальләштерү, тирәнәйтү.
**Практика.** Рәсми эш кәгазьләрен уку, юмористик һәм сатирик әсәрләр уку аша стиль аермалыкларын билгеләү.
**Тема 8.8.** Сөйләшү стиленең фонетик үзенчәлекләре. Дикция өстендә эшләүнең әһәмияте.
**Теория.** Сәхнә теле, интонация турында теоретик белемнәрне актуальләштерү, тирәнәйтү.
**Практика.** Сәхнә теле белән сөйләшү, интонация өстендә эш, баланың сулышта булган кимчелекләрен төзәтү.
**Тема 8.9.** Басым. Артикуляция гимнастикасы. Сузык авазлар.
**Теория.** Басым, сузык аваз, басымлы һәм басымсыз аваз турыда теоретик белемнәрне актуальләштерү, тирәнәйтү.
**Практика.** Артикуляцион гимнастика ясау.
**Тема 8.10.** Артикуляция гимнастикасы. Тартык авазлар.
**Теория.** Тартык авазлар турыда теоретик белемнәрне актуальләштерү, тирәнәйтү.
**Практика.** Артикуляцион гимнастика ясау.
**Тема 8.11.** Тизәйткечләр аша сөйләмне камилләштерү. Халык авыз иҗаты буларак тизәйткечләр турында теоретик белемнәрне актуальләштерү, тирәнәйтү.
**Практика.** Тизәйткечләр уйлап чыгару, фонетик күнегүләр башкару, тиз һәм хатасыз әйтү буенча бәйге оештыру.
**Тема 8.12.** Сәхнә теле логикасы. Интонация. Сулышта булган кимчелекләр.
**Теория.** Сәхнә теле, интонация турында теоретик белемнәрне актуальләштерү, тирәнәйтү.
**Практика.** Сәхнә теле белән сөйләшү, интонация өстендә эш, баланың сулышта булган кимчелекләрен төзәтү.
**Тема 8.13.** Сәнгатьле уку. Күңел, пейзаж, гражданлык лирикасында интонация.
**Теория.** Лирика төрләре (күңел, пейзаж, гражданлык) турында теоретик белемнәрне тирәнәйтү.
**Практика.** Күңел, пейзаж, гражданлык лирикасына кагылган өзекләрне дөрес интонация белән уку, сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру.
**Тема 8.14.** Алынма сүзләр. Алынма сүзләрнең әйтеләше һәм язылышы.

**Теория.** Алынма сүзләр турында теоретик белемнәрне тирәнәйтү. Сүзләрнең кайсы телдән алынырга мөмкинлеге турында белемнәрне актуальләштерү.
**Практика.** Алынма сүзләрнең әйтеләше һәм язылышы өстендә эшләү. Чыганак тел белән чагыштыру, фонетик закончлыкларны билгеләү.
**Тема 8.15.** Урынсыз кулланган рус сүзләре. Гади сөйләм сүзләре һәм диалектизмнар.
**Теория.** Гади сөйләм сүзләре һәм диалектизмнар турында теоретик белемнәрне тирәнәйтү.
**Практика.** Гади сөйләм телендә "артык" сүзләр, бигрәк тә рус сүзләре куллануны тикшерү, радио-телевидение тапшыруларындагы кимчелекләрне барлау, диалектизмнар белән эшләү.
**Тема 8.16.** Кайбер сүзләрнең һәм терминнарның татарчага тәрҗемәләре.
**Теория.** Тәрҗемә һәм терминнар турында теоретик белемнәрне тирәнәйтү.
**Практика.** Тәрҗемә өлкәсенә, бигрәк тә терминнарга караган текстар өстендә эш. Русча-татарча һәм татарча-русча тәрҗемә итү; үзенчәлекләрне, аерма һәм охшаш якларын табу, авыр очракларны ныгыту.
**Тема 8.17.** Морфология күренешләре. Дөрес сөйләм.
**Теория.** Морфология турында теоретик белемнәрне тирәнәйтү.
**Практика.** Дөрес сөйләм булдыру максатыннан, морфологик күренешләрнең кулланылу өлкәсен барлау, мәгънә үзенчәлеген исәпкә алып сөйләм күнекмәләре булдыру.
**Тема 8.18.** Сөйләм культурасы, интонация һәм синтаксис.
**Теория.** Интонация һәм синтаксис турында теоретик белемнәрне тирәнәйтү, аның сөйләм культурасына тәэсирен төшендерү.
**Тема 8.19.** Рус һәм татар теле җөмләләренең кайбер үзенчәлекләре. Тәрҗемә үзенчәлекләре.
**Практика.** Русча-татарча тәрҗемә үзенчәлекләрен исәпкә алып, җөмләләр тәрҗемә итү, "кире тәрҗемә эффекты" белән эшләү күнекмәләре булдыру.
**Тема 8.20.** Сөйләм интонациясе һәм стиль мәсьәләләре. Интонация төзүдә кушымчаларның роле.
**Теория.** Стиль, кушымча төрләре турында теоретик белемнәрне тирәнәйтү.
**Практика.** Кушымча ялгану барышында интонациянең, стильнең үзгәрүен билгеләүче текстлар өстендә эшләү.
**Тема 8.21.** Ярдәмлек сүзләр һәм интонация. Сөйләмнең табигый агышында "артык" сүзләр.
**Теория.** Ярдәмлек сүзләр турында теоретик белемнәрне тирәнәйтү.
**Практика.** Сөйләмнең табигый агышында "артык" сүзләр; "паразит" сүзләрне барлау. Аларны кулланмыйча гына матур сөйләм өлгеләре булдыру.
**Тема 8.22.** Телефоннан сөйләшү этикеты**.**
**Практика.** Телефоннан сөйләшү практикасы булдыру, "артык" сүзләрдән арыну өстендә эшләү.
**Тема 8.23.** Стиль чарасы буларак кабатлаулар, әдәби әсәрдән мисаллар белән ныгыту.
**Теория.** Инверсия турында теоретик белемнәрне тирәнәйтү.

**Практика.** Инверсиянең сөйләм интонациясенә йогынтысын билгеләү, кабатлауларның сөйләм “тәмен” бетерүен төшендерү, сөйләм теленең матур, саф булуы кеше холкын тәрбияләүгә дә турыдын-туры тәэсир итүен ачыклау.
**Тема 8.24.** Сөйләм интонациясе һәм инверсиянең бер-берсенә бәйләнеше.
**Теория.** Инверсия турында теоретик белемнәрне тирәнәйтү.
**Практика.** Инверсиянең сөйләм интонациясенә йогынтысын билгеләү, кабатлауларның сөйләм “тәмен” бетерүен төшендерү, сөйләм теленең матур, саф булуы кеше холкын тәрбияләүгә дә турыдын-туры тәэсир итүен ачыклау.
**Тема 8.25.** Төрле жанрларга аннотация язу: музыка, рәсем, әдәби әсәр, спекакль, балет һ.б.ш.
**Теория.** Аннотация турында теоретик белемнәрне тирәнәйтү.
**Практика.** Музыка, рәсем, әдәби әсәр, спекакль, балет һәм башка жанрдагы әсәрләргә аннотация язу.
**Тема 9.1.** Китапның төзелеше. Төп терминнар
**Теория.** Китапның төзелеше буенча төп терминнар бирү.
**Практика.** Үзләре яраткан китап буенча һәр терминга мисал табып күрсәтү, бәяләү.
**Тема 9.2.** Китап уку кагыйдәләре
**Теория.** Китап уку кагыйдәләре белән таныштыру.
**Практика.** Китап уку планы бирү, шуның буенча эшләү.
**Тема 9.3.** Язучының тормыш юлын өйрәнү планы.
**Теория.** Язучының тормыш юлын өйрәнү планы белән таныштыру.
**Практика.** Язучының тормыш юлын өйрәнү планы бирү, шуның буенча эшләү.
**Тема 9.4.** Яраткан әсәрең турында сөйләү планы.
**Теория.** Яраткан әсәрең турында сөйләү планы белән таныштыру.
**Практика.** Һәр баланың яраткан әсәрен барлау һәм план нигезендә сөйләтү.
**Тема 9.5.** Аннотация, отзыв, конспект, доклад, рецензия, реферат язу.
**Теория.** Аннотация, отзыв, конспект, доклад, рецензия, реферат төрләре белән таныштыру.
**Практика.** Һәр баланың яраткан әсәре нигезендә әлеге жанрларны язу, охшаш һәм аермалы якларын барлау.
**Тема 10.1.** “Юл һәлакәте корбаннары” истәлегенә көзге, кышкы, язгы, җәйге каникуллар алдыннан чара. “Гражданнар оборонасы көне”
**Теория.** Көзге, кышкы, язгы, җәйге каникуллар алдыннан “Юл һәлакәте корбаннары” истәлегенә инструктажны искә төшерү, видеороликлар карау, рәсем ясау, буклетлар эшләү.
**Тема 10.2.** Югары сыйныф укучылары өчен республикакүләм фән олимпиадаларында катнашу.
**Практика.** Олимпиада биремнәрен үтәү.
**Тема 10.3.** Урта сыйныф укучылары өчен республикакүләм фән олимпиадаларда катнашу.
**Практика.** Олимпиада биремнәрен үтәү.
**Тема 10.4.** Башлангыч һәм урта звено укучылары өчен “Фәнгә беренче адым” XI Республикакүләм тикшеренү һәм проект эшләре конференциясе
**Практика.** Олимпиада биремнәрен үтәү.

**Тема 10.5.** “Мин-эзләнүче” X Иделбуе яшүсмерләр фәнни-тикшеренү конференциясендә катнашу.
**Теория.** Конференциядә катнашу өчен материалларга теоретик күзәтү ясау.
**Практика**. Чыгыш ясау.
**Тема 11.** Йомгаклау. Курс буенча проект эше.
**Практика.** Өстәмә занятиеләрдә алган белемнәрнең тормышта кирәклеге, актуальлеген ачучы проект эшләре башкару, яклау.

3.6. ***Методик, дидактик һәм материаль-техник тәэмин ителеш.***

**Кереш занятие**дә аудитор занятие кулланыла, чөнки балалар кереш инструктаж белән танышалар. **Орфографик принциплар, лексикология, морфология, синтаксик берәмлекләр** бүлекләрен өйрәнгәндә практик һәм теоретик формалар куллану отышлы. Бу теоретик белемнәрне практикада ныгыту кирәклеге белән аңлатыла. **Лингвистик анализ, сөйләм культурасы һәм сөйләм стильләре** бүлегендә практик-теоретик формалар белән беррәттән аудитор занятие дә күздә тотыла, чөнки балалар проект эше башкарып, аны яклыйлар. **Табышмаклар** бүлеген китапханәдә ирекле аралашу формасында үткәрү уңайлы. Бу барлык кирәкле материалның кул астында булуы белән аңлатыла. Шулай ук балалар үзләре башкарган проектларны бер-берсенә тәкъдир итәләр, яклыйлар.

***Стимул һәм мотивация тудыру алымнары***:
укуга кызыксыну тудыру
- уку аралашуы;
- мактау;
- уку-танып-белү уеннары;
- уңыш ситуациясе тудыру;
- биремнәрне дифференциаль сайлау

***укуда бурыч һәм җаваплылык хисе тудыру алымнары:***
- мактау;
- уку таләпләрен аңлату;
- үзоешканлык таләп итү

***аңлату-күрсәтү методы:***
- тема буенча уку мәгълүматын хәбәр итү;
- төп теоретик белем бирү;
- өйрәнгән материал белән бәйләнеш булдыру;

***иҗтимагый методлар:***
- үзара ярдәм ситуациясе тудыру;
- элемтә һәм үзара ярдәмләшү;
- нәтиҗәдә кызыксынучанлык;
- үзбәя;
- үзарабәя;

***тикшеренү методы***:
- эксперимент;

- проблемалы анализ

***танып белү методы:***

- халык авыз иҗаты әсәрләрен анализлау;
- проблемалы сораулар тудыру;
- иҗади эшләр башкару

***контроль һәм үзконтроль методы:***

- телдән контроль методы;
- язмача контроль;
- үз һәм үзара контроль.

Дидактик материал төрләре:

- *схематик яки символик (әзер стендлар, планшетлар, таблицалар, схемалар);*
- *картиналы һәм картина-динамикалы (картиналар, иллюстрацияләр, слайдлар);*
- *аваз-тавышлы (видеофильм, мультимедия презентацияләр);*
- *аралаш (телевизион тапшырулар.);*
- *дидактические кхрсәтмшелек (карточкалар, таратма материал);*
- *тематик чыганаклар (җыр, шигырь, экскурсия, сценарий, уен).*

Педагог кулланган методик материал төрләре:

- *методик пособиеләр, төрле эшкәртмәләр, җыентыклар, презентацияләр.*

Материаль-техник тәэмин ителеш:

- занятиеләр класс кабинетында үткәрелә. Эш төреннән чыгып, китапханә яки актлар залы да кулланылырга мөмкин.
- класс кабинетындагы җиһазлар: сыйныф тактасы, парта һәм урындыклар, интерактив такта, мультимедиа җиһазлары, дидактик материал өчен шкаф.

**Тәрбияче өчен кулланылган әдәбият**

1. Вагыйзов С.Г. Кызыклы грамматика. Укытучылар өчен кулланма Казан, «Мәгариф», 2002.
2. Вәлиева Ф.С, Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. Казан, «Раннур», 2002.
3. Ибраһимов С.М. Синтаксик стилистика. Студентлар өчен кулланма. Казан университеты нәшрияты, 1989.
4. Максимов Н. В. Урта мәктәптә татар телен укыту. Укытучылар өчен кулланма. Казан, «Мәгариф». 2004.
5. Максимов Н.А, Трофимова С.М., Хәмидуллина М.З.Татар теленнән дидактик материаллар. Укытучылар өчен кулланма, Казан, “Мәгариф”, 2000.
6. Татар әдәбияты. Теория. Тарих. Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2006.
7. Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теленнән программа: 5-11 нче сыйныфлар.-Казан: Мәгариф, 2010.
8. Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары. 5-11 нче сыйныфлар. Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2010.

9. Хаков В.Х.Татар теле стилистикасы. Укытучылар өчен кулланма, Казан, Татарстан кит., нәшр, 1980.
10. Шакирҗанова Ә.Б. Татар теле орфографиясенең кыен очраклары һәм балаларның грамоталылыгын күтәрү юллары. Казан, Школа, 2009.

**Тәрбияләнүче өчен кулланылган әдәбият**

1. Галиуллина Г.Р. Татар теле, лексикология (таблицалар, схемалар, анализ үрнәкләре, күнегүләр, сүзлекчә).Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2007.
2. Курбатов Хәлиф. Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. “Мәгариф” нәшрияты, 2002.
3. Максимов .Н. В. Татар теленнән тестлар. Уку-укыту ярдәмлеге. Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2008;
4. Ногманова Л.Н., Г.Д.Садыйкова, Г.Г. Минһаҗева Бердәм Республика имтиханына әзерләнәбез. Татар теле. Татар мәктәпләре һәм рус телле мәктәпләрнең татар сыйныфлары өчен. Школа, Казан, 2007.
5. Сафиуллина Ф.С, Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. Урта һәм югары уку йортлары өчен дәреслек, Казан, «Мәгариф», 2002.
6. Сафиуллина Ф.С, Ибраһимов Г.Б. Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел. Казан, 1998.
7. Татар теленнән бердәм Республика имтиханына әзерләнәбез. Татар мәктәпләре һәм рус мәктәпләренең татар сыйныфлары өчен кулланма. Школа, Казан, 2008.
8. Шакирҗанова Ә.Б. Татар теле орфографиясенең кыен очраклары һәм балаларның грамоталылыгын күтәрү юллары. Казан, Школа, 2009.